**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**Түбән Суык-Су авыл җирлеге составына керүче**
**Яңа Мусабай авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# КАРАР

24 ноябрь, 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Яңа Мусабай авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, махсус техника хезмәте күрсәтү.
- Урам яктырткычларын урнаштыру, монтажлау, электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары сатып алу.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **240** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **122** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **122** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **0** кеше тавыш бирде.